ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының
Чуаш Чабаксаркасы авыл җирлегендә

2022 елның 19 ноябре № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Чуаш Чабаксаркасы авыл җирлегендә гражданнар җыены

Карар:

1. Яңа Чишмә муниципаль районының Чуаш Чабаксар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучының тол хатыннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- Пролетарская урамы буенча юл-урам челтәрен (смета буенча юл төзелеше: сатып алу, ташу, вак таш салу, нигез салу, килешү буенча эш өчен түләү) норматив хәлгә китерү;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Чабаксар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда: (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чабаксар авыл җирлеге башлыгы урынбасары
Яңа Чишмә муниципаль районы С.В. Моляков